«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____ И.Г.Һадиуллин
«19» ноября 2025 нче ел

Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен туган (татар) телдән 2026 нчы елда бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2026 году единого республиканского экзамена по родному (татарскому) языку для русскоязычных обучающихся школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА

Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән имтихан эшен башкаруга 180 минут вакыт бирелә. Имтихан эше 4 өлештән тора.

1 нче өлештә 6 бирем тәкъдим ителә (1-6 нчы биремнәр). Алар укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Башкару вакыты – 30 минут.

2 нче өлештә 5 бирем бирелә (7-11 нче биремнәр). Алар укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. Башкару вакыты – 20 минут.

3 нче өлеш 10 биремнән тора (12 –21 нче биремнәр). Алар укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. Башкару вакыты – 30 минут.

4 нче өлеш 6 биремнән тора (22-26 нчы һәм 27 нче биремнәр). Ачык типтагы 22-26 нчы биремнәр сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тота. Башкару вакыты - 30 минут. 27 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүдән гыйбарәт. Башкару вакыты - 40 минут.

Уңышлар телибез!

Инструкция по выполнению работы

На выполнение экзаменационной работы по татарскому языку дается 180 минут. Работа состоит из 4-х частей (27 заданий).

Часть 1 (задания по аудированию) включает 6 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1-6). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 30 минут.

Часть 2 (задания по чтению) включает 5 заданий (задания 7-11). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 20 минут.

Часть 3 (задания по лексике и грамматике) состоит из 10 заданий (задания 12-21). Рекомендуемое время на выполнение – 30 минут.

В части 4 (задания по письму) дано 6 заданий (22-26 и 27). В заданиях 22-26 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией. Рекомендуемое время на выполнение – 30 минут. В задании 27 предлагается написать личное письмо. Рекомендуемое время на выполнение – 40 минут.

Желаем успехов!

1 нче өлеш

Прослушайте 5 коротких диалогов. В заданиях 1-5 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.
Сез биш кыска диалог тыңларсыз. 1-5 нче сорауларга туры килгән җавапны билгеләгез. Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.

1. Балалар китапханәгә нәрсә белән баралар?
1) җәяү
2) автобуста
3) машинада

2. Турист кая барырга тели?
1) Казан Кремленә
2) Милли музейга
3) Сөембикә манарасына

3. Диләрәләр йорты алдында нәрсә бар?
1) мәктәп
2) тукталыш
3) мәчет

4. Сара кайчан йокыдан тора?
1) 6.30
2) 6.00
3) 7.10

5. Әнәс кайда укый?
1) мәктәптә
2) институтта
3) университетта

6. ***Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего А – Г и утверждениями, данными в списке 1 - 6. Используйте каждое утверждение из списка 1-6 только один раз. В задании есть одно лишнее утверждение. Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.***

Сез биш сөйләүчене ишетерсез. 1-6 саннары белән тамгаланган раслауларның кайсы сөйләүчегә туры килүен билгеләгез. Һәр раслауны бер генә тапкыр файдаланыгыз. Бер раслау артык булуын истә тотыгыз. Язманы ике тапкыр тыңларсыз Җаваплarыгызны җаваплар бланкына күчерергә онытмагыз.

1. Сөйләүче апасы турында әйтә.
2.Сөйләүче абыйсы турында әйтә.
3. Сөйләүче энесе турында әйтә
4. Сөйләүче сеңлесе турында әйтә.
5. Сөйләүче әбисе турында әйтә.
6. Сөйләүче бабасы турында әйтә.

Ответ:

Говорящий/ Сөйләүче	**А**	**Ә**	**Б**	**В**	**Г**
Утверждение/ Гыйбарә					

2 нче өлеш

Прочитайте текст. Определите, какие их приведённых утверждений 7-11 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми) и о чём в тексте не сказано (3 – текстта әйтелми).

Текстны укыгыз. 7-11 нче раслауларның текстның эчтәлегенә туры килүен (1 – текстка туры килә), туры килмәвен (2 – текстка туры килми) һәм текстта бу турыда мәгълүмат бирелмәвен (3 - текстта әйтелми) күрсәтегез.

Закировлар – Чистай ягы кешеләре. Алар – Нарат-Елга авылында ишле гаиләдә туып-үскән егетләр. Мәктәпне тәмамлагач, Казанның химия технология институтында укыганнар. Ул елларда татар мәктәбен тәмамлагач, техник вузга укырга керү бик авыр иде. Институтны бетергәч, һәр кешенең индивидуаль хезмәт юлы башлана. Холыклары белән бер-берсеннән шактый аерылсалар да, Шамил белән Ринатның вуз бетергәннән соң да укуларын дәвам итәләр. Шамил Ленинградта аспирантура тәмамлый, Ринат фәннәр кандидаты була. Икесе дә комсомол булалар, партия мәктәбен үтәләр, район һәм өлкә комитетларында эшлиләр. Икесе дә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм директор булып эшлиләр.

Бертуган Закировларны мин кырык еллап беләм. Шамил белән без алданрак таныш идек. Ул институтның актлар залында татар яшьләре белән төрле очрашулар оештыра иде. Анда җырчы Илһам Шакиров, композитор Ренат Еникеев, язучы Роберт Батулла, яшь шагыйрьләр чыгыш ясый иде.

(Равил Фәйзуллинан)

7. Шамил белән Ринат Чистай районында туганнар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

8. Бу – игезәк егетләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

9. Егетләр бер мәктәптә, бер үк укытучыларда укыганнар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

10. Егетләр, институтка укырга керү өчен, русча сочинение язганнар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

11. Химия технология институтына укырга керү җиңел булган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

3 нче өлеш

Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 12 – 16 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами.

Текстны укыгыз. 12-16 нчы биремнәрдә икенче баганада бирелгән сүзләрне җөмләдә кирәкле грамматик формага куегыз. Буш урыннарга языгыз.

12.	... йөреп арыгач, күкне күзәтүе бик кызык.	СӘЯХӘТ
13.	... нәрсәләр бар икән?	КҮК
14.	Болытлар ... менеп, сәяхәт итеп йөрсәң икән.	ӨС
15.	Менә бу сәяхәт ... иде!	БУЛЫРГА
16.	Менәрбез дә, ... да өлгерербез, хыялларыбыз зур!	БАРЫСЫ

Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 17 – 21 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию.

Текстны укыгыз. 17-21 нче биремнәрдә икенче баганада бирелгән сүзләргә, ясагыч кушымчалар ялгап, яңа сүзләр ясагыз. Аларны җөмләдә кирәкле грамматик формага куеп языгыз. Һәр буш урын аерым биремгә туры килә.

17.	- Нәрсә соң ул ... ?	БАЙ
18.	Малай әтисенә шундый ... бирде.	СОРА
19.	- Кешегә ... барлык нәрсә – байлык, улым.	КИРӘК
20.	Менә бу өстәл дә, синең китапларын да, алган ... дә – байлык.	БЕЛ
21.	Син, улым, байлык … йөргәндә, сәяхәткә чыкканда, иген үстерүчене, туган туфрагыңны онытма.	ЭЗ

4 нче өлеш

Для ответа на задания 22-26 и 27 используйте бланк ответов № 2. При выполнении заданий 22-26 и 27 обратите внимание на то, что ваши ответы будут оцениваться только по записям, сделанным на бланке № 2. Записи в черновиках при проверке экспертом не учитываются.
Соблюдайте указанный объём письменной работы 27 (70–80 слов).

22-26 һәм 27 нче биремнәрне үтәү өчен, 2 нче номерлы җавап бланкларын файдаланыгыз. Җаваплар әлеге бланкларда язылганнар буенча тикшереләчәк. Караламадагы язмалар тикшерелми.
27 нче биремне үтәгәндә, язма эшнең күләмен истә тотыгыз (70-80 сүз).

Напишите реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.

Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.

22. Сообщите родственникам, что вы во время зимних каникул съездили в Санкт-Петербург с классом.

23. Спросите у друга (подруги), где и с кем он (она) посмотрел(а) новый фильм Фёдор Бондарчука.

24. Предложите младшему брату сходить в цирк зверей и посмотреть новую программу.

25. Попросите бабушку связать вам новый шарф.

26. Поздравьте папу с новым автомобилем.

27. Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез **70 – 80** сүздән торырга тиеш.

... Мин тәмле ашарга яратам. Ризык әзерләү турында тапшырулар карыйм, рецептлар өйрәнәм, үзем дә пешерергә яратам. Мин пешергән ризыклар әти-әниемә дә, туганнарыма да ошыйлар. Ләкин мин татар ашларын әбием һәм әнием кебек оста әзерли алмыйм әле. Алар пешергәннәр күпкә тәмлерәк була. Мин киләчәктә пешекче булырга телим...

... Ә сиңа нинди ризыклар ошый?... Син нинди ризыклар пешерә беләсең? ... Синеңчә, оста пешерү өчен нишләргә кирәк?...

ҖАВАПЛАР

Биремнәр	Дөрес җавап
1	1
2	2
3	3
4	1
5	2
6	21435
7	1
8	2
9	3
10	3
11	2
12	СӘЯХӘТТӘ
13	КҮКТӘ
14	ӨСТЕНӘ
15	БУЛЫР
16	БАРЫСЫНА
17	БАЙЛЫК
18	СОРАУ
19	КИРӘКЛЕ
20	БЕЛЕМЕҢ
21	ЭЗЛӘП

22-26 нчы биремнәрне бәяләү критерийлары
Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу

№	*Бәяләү критерийлары*	*Баллар*
I	***Язылган текстның эчтәлеге***	
К1	**Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру**	
	Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган. Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән. Фактик хаталар юк.	1
	Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган. ***Яки*** Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган **Яки** дөрес формалаштырмаган. Яки Фактик хаталар бар. ***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**.	0
II	***Грамоталылык***	
К2	**Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше**	
	Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган хаталар (грамматик, орфографик, стилистик. пунктуацион) юк. ***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар.	1
	Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар. **Яки** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**.	0
Язма эш өчен максималь балл		2

Шәхси хат язуны (27нче биремне) бәяләү критерийлары

К	Бәяләү критерийлары	3 балл	2 балл	1 балл	0 балл
К1	Коммуникатив бурычны үтәү	***Эш тулысынча башкарылган***: 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, исәнләшү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән.	***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән.	***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган.	***Эш башкарылмаган***: 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый.
К2	Текстны оештыру		Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә.	Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар.	Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми.
К3	Текстның лексик-грамматик төзелеше	Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә).	Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик	Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган	Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк.

			чаралар кулланылган.	1-2 грамматик хата бар.	
К4	Орфография һәм пунктуация		Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар.	Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар.	Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк.

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса), бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **40** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

Аудиоязмалар өчен текстлар

Инструктор. Сез биш кыска диалог тыңларсыз. 1-5 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.
Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.

Инструктор. Беренче диалог.

Илназ: Динә, миңа китапханәгә барырга кирәк. Син минем белән барырга телисеңме?
Динә: Әйе, Илназ. Синең кайсы китапханәгә барасың?
Илназ: Татарстан урамындагы зур китапханәгә. Анда балалар һәм өлкәннәр өчен махсус заллар бар.
Динә: Аңладым. Без анда автобуста барабызмы, җәяүме?
Илназ: Җәяү барырга да мөмкин. Бүген һава торышы әйбәт.
Динә: Мин риза. Китапханә сәгать ничәдән эшли башлый?
Илназ: Иртәнге уннан кичке җидегә кадәр эшли. Чәршәмбе һәм шимбә – ял көннәре.
Динә: Ярый, хәзер сәгать унбер инде. Хәзер киенәм дә, чыгам. Мине машина янында ишегалдында көт.

Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.
[язма икенче тапкыр яңгырый]

[2 секунд пауза]
Инструктор.Икенче диалог

Турист: Мин Казанның тарихи урыннарын, музейларын карарга телим. Әйтегезче, шәһәрдә нинди истәлекле урыннар бар?
Илнур: Шәһәр үзәгендә Кабан күле бар. Музейлар да күп. Казансу елгасы буенда Казан Кремле урнашкан. Кремль янында Муса Җәлилгә һәйкәл куелган. Җиде катлы Сөембикә манарасы аеруча матур.
Турист: Гафу итегез, Кремльгә кадәр ничәнче автобус яки трамвай йөри яисә җәяү барып буламы?
Илнур: Юк, җәяү ерак. Казан Кремленә метрода барырга мөмкин.
Турист: Ә кайсы тукталышта төшәргә кирәк?
Илнур: “Кремль” станциясендә чыксагыз, уңайлы булачак.
Турист: Минем Татарстан Республикасының Милли музеена да барасым килә.
Илнур: Музей Казан Кремленең Спас манарасы каршында урнашкан
Турист: Музейның эш вакытын һәм билет бәясен белмисезме?
Илнур: Музей уннан алтыга кадәр эшли. Дүшәмбе – ял көне. Билет бәясе 50 сумнан 150 сумга кадәр.
Турист: Рәхмәт Сезгә!
Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.
[язма икенче тапкыр яңгырый]

[2 секунд пауза]

Инструктор. Өченче диалог

Риф: Син кайда яшисең, Диләрә?
Диләрә: Мин Казан шәһәрендә яшим.
Риф: Кайсы урамда торасың?
Диләрә: Мулланур Вахитов урамында яшим.
Риф: Ә кайсы йортта?
Диләрә: Мин бу тугыз катлы йортның бишенче катында торам, Риф. Йортыбыз яңа, биек, матур. Ул мәчет артында урнашкан. Мәктәпкә кадәр өйдән бик ерак түгел, ике тукталыш кына. Көн аяз булганда, мин укырга җәяү йөрим. Яңгыр яуса, автобуста барам.
Риф: Фатирыгыз ничә бүлмәле?
Диләрә: Фатирыбыз өч бүлмәле.
Риф: Өч бүлмәле? Алайса иркен инде?!
Диләрә: Әйе, безнең гаиләбез дә зур бит.
Риф: Фатирыңда иң яраткан урын кайда?Аш бүлмәседер әле?
Диләрә: Әйе! Каян белеп әйтәсең?! Иң мөһиме: аш бүлмәсе иркен. Без гаилә белән бергә җыелышып чәй эчәргә яратабыз.

Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.
[язма икенче тапкыр яңгырый]

[2 секунд пауза]
Инструктор. Дүртенче диалог

Сара: Мансур, син иртән сәгать ничәдә торасың?
Мансур: Сәгать алтыда, Сара. Ә син?
Сара: Мин алтыда уянам, ләкин җиденче яртыда гына торам.
Мансур: Син дәресләргә соңга калмыйсыңмы? Торгач, юынырга, күнегүләр ясарга, киенергә, ашарга да кирәк бит.
Сара: Юк, соңга калмыйм. Без мәктәпкә якын яшибез. Мин өйдән мәктәпкә кадәр 5 минутта барып җитәм.
Мансур: Бу бик әйбәт, Сара. Кызганычка каршы, миңа мәктәпкә автобуста ярты сәгать барырга кирәк. Шуңа күрә мин җиде сәгать ун минутта өйдән чыгам. Ә син, Сара, мәктәпкә җәяү барасыңмы?
Сара: Әйе, әлбәттә. Мансур.

Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.
[язма икенче тапкыр яңгырый]

[2 секунд пауза]

Инструктор. Бишенче диалог

Әнәс: Исәнмесез, Алсу Маратовна! Хәлләрегез ничек?
Алсу Маратовна: Исәнме, Әнәс, рәхмәт! Синеке ничек? Укырга кая кердең?
Әнәс: Хәлләрем яхшы, рәхмәт! Әйбәт кенә укып йөрим. Мин институтка укырга кердем.
Алсу Маратовна: Мин синең өчен бик шат. Бик әйбәт булган.
Әнәс: Мин сезнең дәресләрегезне бик сагынам.Сез - минем иң яраткан укытучым идегез.
Алсу Маратовна: Рәхмәт инде, Әнәс. Сез дә минем яраткан сыйныфым, син иң яраткан укучым идең. Уку йортына автобус белән барасыңмы яки трамвай беләнме?
Әнәс: Мин башта автобус белән барам, Кәҗә бистәсе станциясендә метрога утырам. Тукай мәйданы станциясеннән 5 минут җәяү киләм. Бик уңайлы. Юлга 30 минут вакыт уза.
Алсу Маратовна: Мин дә эшкә метро белән йөрим.
Әнәс: Сау булыгыз, Алсу Маратовна. Минем автобусым килә. Ашыгам.
Алсу Маратовна: Сау бул, Әнәс. Очрашуыбызга мин бик шат. Уңышлар сиңа!
Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.
[язма икенче тапкыр яңгырый]

6 . Инструктор. Сез биш сөйләүчене ишетерсез. 1-6 саннары белән тамгаланган раслауларның кайсы сөйләүчегә туры килүен билгеләгез. Һәр раслауны бер генә тапкыр файдаланыгыз. Бер раслау артык булуын истә тотыгыз. Язманы ике тапкыр тыңларсыз. Җаваплarыгызны җаваплар бланкына күчерергә онытмагыз.

Сөйләүче А
Ул әниeм белән әтиемнең олы уллары. Ул институтта укый, төзүче булырга тели. Ул миннән биш яшькә зуррак. Ул бик акыллы, тапкыр һәм тырыш. Ул бик күп укый, спорт белән шөгыльләнергә ярата. Мине футбол, хоккей уйнарга өйрәтте. Без аның белән җәен велосипедта йөрергә, ә кышын чаңгы шуарга яратабыз.
[2 секунд пауза]

Сөйләүче Ә
Ул – миннән ике яшькә зур. Аның чәчләре озын, кара төстә, күзләре дә кара. Ул миңа элек дәресләремне әзерләргә ярдәм итә иде. Ул - бик тырыш, чибәр һәм пөхтә туташ. Мин ул пешергән коймакларны, кыстыбыйларны ашарга яратам. Ул, әниeм өйдә булмаганда, безгә кичке аш әзерли, күлмәкләрне, итәкләрне үтүкләп бирә,безне һәрчак кайгырта.
[2 секунд пауза]

Сөйләүче Б

Ул бик кечкенә әле, аңа бары өч кенә яшь. Ләкин мин аны бик яратам. Ул һәрвакыт минем арттан “абый, абый” дип йөгерә, үзе белән уйнавымны, аңа китап укуымны тели. Бу кечкенә туташ мультфильмнар карарга ярата, курчаклары белән уйный аларны киендерә, ашата, йоклата. Тиздән ул балалар бакчасына барачак.

[2 секунд пауза]

Сөйләүче В

Ул миннән ике яшькә генә кечкенә, минем чын дустым. Кечкенә вакытта без аның белән еш кына сугыша, әйберләрне бүлешә алмый идек. Ә хәзер без гел бергә: мәктәпкә дә бергә йөрибез, уйнарга да бергә чыгабыз, спорт секциясенә дә бергә барабыз. Ул математика һәм информатиканы бик яхшы белә. Без бер-беребезгә бик охшаганбыз. Кайвакыт күршеләр безнең исемнәрне дә бутыйлар, шуңа күрә “Малайлар” дип кенә эндәшәләр.

[2 секунд пауза]

Сөйләүче Г

Ул - безнең гаиләдә иң өлкән хатын-кыз. Ул - әтиемнең әнисе. Аңа инде 82 яшь. Ул безнең белән яши, чәчәкләр, гөлләр ярата, шуңа күрә аларны үстерә. Ә без аны бик яратабыз. Ул безне тәмле ризыклар белән сыйлый, энем белән сеңелемә әкиятләр сөйли, безгә һәрвакыт яхшы теләкләр теләп тора. Мәктәптән кайтканда безне каршы ала. Без аңа сәламәтлек һәм озын гомер телибез.

[2 секунд пауза]

Инструктор. Язманы икенче тапкыр тыңлагыз.

[язма икенче тапкыр яңгырый]